ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ЛЕНИНОГОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

«ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.11.2023 г.Лениногорск № 4815

Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «Лениногорск муниципаль районында җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары буенча хәрәкәт иткәндә авыр йөкле транспорт чаралары китергән зыянның күләмен билгеләү турында» 2022 елның 28 сентябрендәге 970 номерлы карарының үз көчен югалтуын тану хакында

«Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2023 елның 20 июнендәге 46-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына таянып, Лениногорск муниципаль районы муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «Лениногорск муниципаль районында җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары буенча хәрәкәт иткәндә авыр йөкле транспорт чаралары китергән зыянның күләмен билгеләү турында» 2022 елның 28 сентябрендәге 970 номерлы карарының үз көчен югалтуын танырга.
2. Әлеге карар 2024 елның 1 мартыннан үз көченә керә.
3. Әлеге карарны «Лениногорские вести» газетасында бастырып чыгарырга, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Лениногорск муниципаль районы»муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының эшләр идарәчесенә йөкләргә.

Җитәкче З. Г. Михайлова

Галимова Л.М.
5-44-72